**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Яңа Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге составына керүче Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә торак пунктларында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**№2** **22 октябрь 2021 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге составына керүче Утыз Имән, Кызыл Чишмә авылы торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым **кертергә**, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш.
2. Алынган чараларны җибәрергә:

-Утыз Имән торак пунктында "Чәчәкле алан" чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- МТЗ-82 тракторы өчен 2 ПТС -4 трактор арбасы сатып алу.
- Утыз Имән торак пунктында Совет урамында, 200 метр Пионерская урамында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: (20-30 мм фракциясендә вак таш сатып алу)

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы

Яңа Кади авыл җирлеге башлыгы М.М.Әминов